Бар шунда-белмим кая,

китер шуны-белмим нине

Татгосиздат 1951

Бар шунда-белмим кая,

китер шуны-белмим нине

РУС ХАЛЫК ӘКИЯТЕ

А. ТОЛСТОЙ
ЭШЛӘНЕШЕНДӘ

Ш. ЗӘЙНИ
ТӘРҖЕМӘСЕ

ТАТГОСИЗДАТ
ЯШЬЛӘР-БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫ СЕКТОРЫ
КАЗАН 1951

★
Җаваплы редакторы
Р. Гыйззәтуллина
★★
Художник *Е. Эндриксон*
рәсемнәре
★★
Тышлыкны
художник *Л. Муллинова*
эшләде
★★
Художество редакторы
М. Рәхимов
★

Ниндидер бер патшалыкта өйләнмәгән бер патша яшәгән. Аның Андрей исемле укчысы булган.

Бервакыт укчы Андрей ауга чыккан. Көн озын урман бетереп йөргән, ләкин бер генә кош та очрата алмаган. Вакыт кичке якка авышкан. Андрей күңелсезләнеп кайтыр юлга чыккан һәм шунда агач башында утырган кыр күгәрчененә күзе төшкән.

— Кая булмаса, шушы күгәрченне генә булса да атып алыйм,—дип уйлаган ул.

Аткан. Яраланган күгәрчен агач башыннан юеш җиргә егылып та төшкән. Андрей аны күтәреп алган да, башын өзеп, букчасына салырга теләгән. Ләкин шул чакта күгәрчен телгә килеп, аңа болай дигән:

— Үтермә син мине, укчы Андрей, харап итмә син минем башымны. Тере килеш өеңә алып кайт, тәрәзә төбеңә утырт һәм йокыга киткәнемне сагалап тор да, уң кулың белән бик каты кизәнеп, сугып җибәр. Шунда син үзеңә бетмәс-төкәнмәс зур бәхет табарсың.

Хәйран калган укчы Андрей: Бу ни хәл? Күрер күзгә үзе кош кебек, сөйләр сүзе гел кеше кебек, — дип күгәрченне өенә алып кайткан, тәрәзә төбенә утырткан да, йоклап китүен көтеп тора башлаган.

Күп тә үтмәгән, күгәрчен, башын канат астына тыгып, йокыга талган. Андрей аның әйткәннәрен исенә алып, уң кулы белән бик каты кизәнеп сугып җибәргән. Күгәрчен җиргә авып төшкән һәм дөньяда охшашы, тиңдәше күрел-

мәгән, әкиятләрдә генә сөйләргә мөмкин булган матур кызга — Мария-царевнага әверелгән.

Шунда Мария-царевна укчыга болай дигән:

— Син мине әләктерә белдең, тота да бел. Җайлап кына туй яса, сый-хөрмәт үткәр. Мин сиңа турылыклы, шат күңелле хатын булырмын.

Килешкәннәр алар. Укчы Андрей Мария-царевнага өйләнгән һәм яшь кәләш белән гөрләшеп яши башлаган. Андрей хезмәтен дә онытмаган. Көн саен иртә таңнан торып урманга киткән, кошлар атып, аларны патша ашханәсенә ташый торган булган.

Күп тә үтмәгән, Мария-царевна укчыга болай дигән:

— Ярлы яшисең син, Андрей!

— Әйе, үзең күргәнчә инде.

— Бар, йөз сум акча тап һәм шул акчага төрле-төрле ефәкләр сатып алып кайт. Калганын үзем рәтләрмен.

Андрей аның сүзен тыңлаган, иптәшләренә барып, кайсыннан бер, кайсыннан ике сум акча бурычка җыйган да хатынына төрле-төрле ефәкләр сатып алып кайткан. Мария-царевна ефәкләрне алган да, әйткән:

— Инде ят та йокла, иртә кичтән хәерлерәк.

Андрей ятып йоклаган, ә Мария-царевна төн буе утырып, бер палас тукыган. Паласта бөтен патшалык; таулар, урманнар, кырлар, күктә кошлар оча, тауларда — җанварлар, диңгезләрдә — балыклар, әйләнәсендә ай белән кояш сурәтләнгән, мондый гүзәл паласны әлегә дөньяда берәү дә күрмәгән булган.

Иртәгесен Мария-царевна паласны иренә биреп:

— Сәүдә рәтенә бар. Менә моны сәүдәгәрләргә сат. Тик кара, бәясен үзең сорама, күпме бирсәләр, шуны ал.

Андрей, паласны беләгенә салып, сәүдә рәтенә барган.

Аның янына бер сәүдәгәр йөгереп килгән:

— Кара әле, хөрмәтлем, күпме сорыйсың?

— Син сәүдә кешесе, үз бәяңне бир.

Сәүдәгәр уйлаган-уйлаган, ләкин бәя куя алмаган. Алар янына тагын берсе, икенчесе килгән. Бара-тора Андрейны сәүдәгәрләр талпасы сырып алган. Барысы да паласка караганнар да таңга калганнар. Ә бәя куя алмаганнар.

Шул чакта болар яныннан патша киңәшчесе узып бара икән. Ул сәүдәгәрләрнең нәрсә сатулашуларын белергә теләгән. Каретасыннан төшкән дә, көч-хәл белән ырып-ерып халык арасына кергән һәм:

— Исәнмесез, сәүдәгәрләр, диңгез арты кунаклары! Нәрсә сатулашасыз? — дип сораган.

— Алай итәбез, болай итәбез, менә бу паласка бәя куя алмыйбыз! — дигәннәр.

Патша киңәшчесе паласка күз төшергән һәм аның да исе киткән:

— Әйт әле, укчы, чын дөресен генә, мондый гүзәл паласны каян алдың?

Укчы:

— Хатыным чикте, — дигән.

Күпме бирим соң сиңа моның өчен?

— Мин үзем дә белмим. Хатын сатулашмаска, күпме бирсәләр, шуны алырга кушты.

— Менә сиңа, укчы, ун мең сум акча.

Андрей акчаны алып, паласны биргән дә, кайтып киткән. Ә патша киңәшчесе сарайга барып, патшага паласны күрсәткән. Патша паласка караган да, үз патшалыгын уч төбендә кебек күреп, аһ орган һәм:

— Син теләсәң ни эшлә, мин сиңа бу паласны бирмим, — дигән.

Патша үзенең киңәшчесенә егерме мең сум акча чыгарып тоттырган.

Киңәшче акчаны алган һәм:

„Зарар юк, мин үземә икенчесен, тагын да шәбрәген эшләтермен“, — дип уйлаган.

Каретасына утырган да, бистәгә чапкан. Андрей укчы тора торган өйне эзләп тапкан. Ишеген шакыган. Мария-царевна аңа ишек ачкан. Патша киңәшчесе аны күргәч, бер аягын эчкә атлап, икенчесен тышта калдырган килеш, катып калган. Нәрсә өчен килүен дә оныткан. Аның алдында шундый бер матур басып тора икән, ул, аңардан күзен ала алмаслык булып, караган да калган.

Мария-царевна бу ни әйтер икән дип, көткән-көткән дә, җилкәсеннән төртеп, тышка чыгарган һәм ишекне ябып куйган. Киңәшче, көч-хәл белән аңына килеп, теләр-теләмәс кенә, өенә кайтып киткән.

Шул көннән соң киңәшченең ашаганы — аш түгел, эчкәне — эчү түгел икән. Укчының хатыны аның күз алдыннан китми дә китми, ди.

Патша бу хәлгә игътибар иткән һәм: „Нәрсә булган аңа?“ — дип сорашкан.

Киңәшче патшага болай дип җавап биргән:

— Аһ, падишаһым, мин бер укчының хатынын күрдем. Шуннан бирле көне-төне шул хатын турында гына уйлыйм! Ашаганым — аш, эчкәнем — су түгел, бернинди им-том да, сихер дә ярдәм итми, — дигән.

Патшаның үзенең дә укчының хатынын барып күрәсе килгән. Ул гади кеше киемнәре киеп бистәгә барган. Укчы Андрейның өен эзләп табып, ишеген шакыган. Мария-царевна аңа ишек ачкан. Патша аны күргәч, бер аягын эчкә атлап, икенчесен тышта калдырган килеш, таш кебек катып калган. Аның алдында әйтеп бетергесез гүзәл басып тора икән.

Мария-царевна көткән-көткән дә, патшаның җилкәсеннән төртеп тышка чыгарган һәм ишекне ябып куйган.

Патшаның йөрәген мәхәббәт уты чолгап алган.

— „Нәрсәгә мин өйләнмичә хатынсыз йөрим? Менә бу гүзәлгә өйләнәсе бар. Аңа укчы хатыны булырга түгел, патша хатыны булырга язган“, — дип уйлаган ул.

Патша сараена кайткан һәм: „Бу хатынны иреннән тартып алырга кирәк“, — дигән бозык уйга килгән. Киңәшчесен чакырган да:

— Укчы Андрейны юк итү юлын эзләп тап. Мин аның хатынына өй-

ләнергә телим. Юлын тапсаң — шәһәрләр, авыллар белән, алтын хәзинә белән бүләкләрмен, тапмасаң — башыңны кисәрмен! — дигән.

Киңәшче тирән кайгыга батып, борынын сузып чыгып киткән һәм кайгыдан аракы эчәргә дип бер кабакка кергән.

Аның янына ертык чикмән кигән ялагай бер эчкече йөгереп килгән:

— Нәрсә турында кайгырасың, патша киңәшчесе, нигә болай борыныңны суздың? — дигән.

— Күземнән югал, кабак хәшәрәте!

— Ә син мине кума, берәр стакан аракы салып бирсәң, тагын да яхшырак булыр. Мин сиңа акыл өйрәтермен.

Патша киңәшчесе аңа аракы салып биргән һәм кайгысын сөйләгән.

Эчкече аңа:

— Укчы Андрейны юлдан алу авыр эш түгел. Ул үзе беркатлы гади кеше. Ә хатыны аның хәйләкәрнең дә хәйләкәре. Я, ярый, без шундый табышмак уйлап чыгарырбыз, ул да бу табышмакның очына чыга алмас. Бар кайт та, патшаңа әйт: — Ул, укчы Андрейны теге дөньяга, әтисе мәрхүм патшаның хәлен белергә җибәрсен. Андрей шунда китәр дә кире әйләнеп кайтмас.

Киңәшче эчкечегә рәхмәт әйтеп, патша янына йөгереп кайткан:

— Укчыны юк итәргә мөмкин, — дип эчкече белән булган эшне сөйләп биргән һәм Андрейны кая, ни өчен җибәрергә кирәклеген өйрәткән. Патша шатланган һәм шунда ук укчы Андрейны чакыртып китергән:

— Я, Андрей, — дигән патша, — син миңа чын күңелдән, турылык белән хезмәт иттең. Инде тагын бер йомышымны үтә. Теге дөньяга бар да, минем мәрхүм әти — карт патшаның хәлен белеп кайт. Белмәсәң — менә хәнҗәрем, башыңны өзәрмен, — дигән.

Андрей кайгыга батып өенә кайткан, башын аска игән. Мария-царевна аңардан:

— Нигә болай күңелсез утырасың? Әллә берәр хәл бармы? — дип сораган.

Андрей аңарга, патшаның үзенә нинди эш кушканын сөйләп биргән. Мария-царевна:

— Тапкансың кайгырырлык эш! Эшмени бу! Бу әле аның баласы гына, алда булыр әле аның анасы. Бар ятып йокла, иртә кичтән хәерлерәк — дигән.

Иртә таңнан, Андрей әле юньләп уянырга да өлгермәгән, Мария-царевна аңа бер капчык сохари белән алтын балдак тоттырып:

— Бар патша янына һәм үзеңә юлдаш итеп патша киңәшчесен сора. Югыйсә, минем теге дөньяда булуыма сез ышанмассыз, дип әйт. Ә юлга чыккач, шушы балдакны алдыңнан тәгәрәт, ул сине алып барып җиткерер! — дигән.

Андрей бер капчык сохари белән балдакны алган да, хатыны белән саубуллашып, патшадан үзенә юлдаш сорарга киткән. Бер ни эшләр хәл юк. Патша риза булган. Киңәшчегә Андрей белән бергә теге дөньяга китәргә боерык биргән.

Менә алар икәүләп юлга чыкканнар. Андрей балдагын ташлаган. Балдак тәгәри башлаган. Аның артыннан Андрей киткән. Алар матур кырлар, мүкле

сазлыклар, елгалар, күлләр аша үткәннәр. Патша киңәшчесе дә артларыннан өстерәлә икән.

Арысалар, туктап сохари ашаганнар, аннан юлны яңадан дәвам иттергәннәр алар.

Ай киткәннәр, ел киткәннәр, бара-бара бер куе карурманга барып җиткәннәр. Тирән яр астына төшкәннәр. Шунда балдак туктаган.

Андрей белән патша киңәшчесе сохари ашарга утырганнар. Карасалар, ни күзләре белән күрсеннәр, ике җен, карт патшаны гаять зур арбага җигеп, утын алып кайтып баралар икән. Аларның берсе уң ягыннан, икенчесе сул ягыннан патшаны күсәкләр белән тукмыйлар икән.

Андрей:

— Кара әле, бу безнең мәрхүм патша бабай түгелме соң? — дигән.

— Дөрес әйтәсең, нәкъ шул үзе, утын ташый! — дигән киңәшче.

Андрей җеннәргә кычкырган:

— Әй, хөрмәтле җен әфәнделәр! Бу үләксәне, беразга гына булса да, безнең янга җибәрегез әле! Минем аннан сорыйсы сүзләрем бар.

Җеннәр җавап биргәннәр:

— Көтеп торырга вакытыбыз бар ди безнең! Утынны үзебез тартып китәр дисеңме әллә?

— Ә сез миннән алмашка икенче кеше алып торыгыз.

Җеннәр карт патшаны тугарганнар да, патша киңәшчесен җигеп, ике яклап күсәкли-күсәкли куа башлаганнар. Теге бөгелә-сыгыла, ләкин тартмый чарасы юк.

Андрей карт патшаның хәлен сораша башлаган.

— Ах, укчы Андрей, теге дөньяда хәлем бик начар минем, — дип җавап биргән патша, — улыма сәлам әйт, мин аңа бик каты наказ бирәм, кешеләрне рәнҗетмәсен, югыйсә аңа да шушындый ук хәл булачак.

Алар сүзләрен бетереп тә өлгермәгәннәр, җеннәр инде буш арба белән килеп тә җиткәннәр. Андрей, карт патша белән саубуллашкан һәм патша киңәшчесен үзе белән алып, кайтырга чыккан. Алар үз патшалыкларына килеп җиткәннәр һәм патша сараена барганнар. Патша укчыны күргәч, ачу белән аңа ташланган:

— Син ничек әйләнеп кайтырга батырчылык иттең?

Укчы Андрей җавап биргән:

— Алай иттем, болай иттем, мин теге дөньяга синең мәрхүм атаң янына барып кайттым. Ул бик начар хәлдә яши икән. Сиңа сәлам әйтергә кушты һәм кешеләрне рәнҗетмәсен дип бик нык әйтеп җибәрде.

— Ә син теге дөньяга баруыңны һәм минем әтиемне күрүеңне нәрсә белән исбат итә аласың?

— Җеннәр күсәгеннән төшкән эзләр, киңәшчеңнең аркасында әлегә кадәр саклаланалар. Исбат итү өчен шулар җитсә кирәк.

Патшага ышанудан башка нәрсә калмаган. Ул Андрейны өенә җибәргән дә, киңәшчесенә болай дигән:

— Укчыны юк итү юлын тап. Югыйсә минем хәнҗәр, синең башыңны өзәр!

Патша киңәшчесе башын тагын да түбәнрәк салындырып чыгып киткән. Кабакка барып кергән һәм аракы сорап алган. Аның янына теге эчкече тагын килеп җиткән.

— Нәрсәгә болай кайгыга баттың, патша киңәшчесе? Салып бир миңа бер стакан тутырып, мин сиңа акыл өйрәтим! — дигән.

Киңәшче аңа аракы салып биргән һәм кайгысын сөйләгән.

Эчкече аңа:

— Бар кайт та, патшага әйт: ул, укчыны тагы Каф тавы артына, андагы утызынчы патшалыктан мәче-баюнны табып алып кайтырга җибәрсен. Мондый эшне үтәү түгел, уйлап чыгару да читен дигән.

Киңәшче кабаланып патша янына йөгергән һәм укчыны әйләнеп кайтмаслык итәр өчен, кая җибәрергә, нинди эш кушарга кирәген әйткән. Патша Андрейны чакырткан:

— Я, Андрей, син минем бер йомышымны үтәдең, инде икенчесен дә башкар: утызынчы патшалыкка барып, мәче-баюнны алып кайт! Алып кайтмасаң, менә бу хәнҗәр синең башыңны өзәр.

Андрей, башын тагын да түбәнрәк иеп, өенә кайткан һәм хатынына патша приказын сөйләп биргән.

— Таптың көенерлек нәрсә! — дигән Мария-царевна, — бу әле эш түгел, эшнең баласы гына, алда әле аның анасы. Бар ятып йокла, иртә кичтән хәерлерәк.

Андрей йокларга яткан, ә Мария-царевна тимерче алачыгына барып, аларга өч тимер башлык, бер тимер кыскыч һәм өч чыбык коярга кушкан. Чыбыкларның берсе — тимердән, икенчесе — бакырдан, өченчесе — аккургаштан булсын, дигән.

Иртә таңнан Мария-царевна Андрейны уяткан:

— Менә сиңа өч башлык, бер кыскыч һәм өч чыбык. Каф тавы артына, утызынчы патшалыкка кит. Барып җитәргә өч чакрым җир калгач, сине бик каты йокы баса башлар. Мәче-баюн сине йоклатырга теләр. Син йоклама, кулларыңны бер-берсенә сук, аякларыңны бер-берсенә абындыр, ә кай җирдә тәгәрәп-тәгәрәп тә киткәлә. Әгәр йокласаң, мәче-баюн сине үтерәчәк.

Мария-царевна аңа тагын нәрсә эшләргә кирәген өйрәткән дә, юлга озаткан.

Әкият тиз сөйләнсә дә, эш алай тиз эшләнми. Укчы Андрей, бара торгач, утызынчы патшалыкка якынлашкан.

Өч чакрым калды дигәндә, аны йокы баса башлаган. Андрей башына өч тимер башлыгын кигән, кулларын бер-берсенә суга-суга, аякларын абындыра-абындыра, кай җирдә тәгәри-тәгәри баруында дәвам иткән.

Ничек итте-алай йокысын җиңгән һәм бик биек бер багана алдына барып чыккан.

Мәче-баюн, Андрейны күргәч, мыяулаган, мыраулаган да багана өстеннән

Андрейның башына сикергән. Башлыкларның берсен ваткан, икенчесен ваткан, өченчесен ватам дигәндә, Андрей аны кыскыч белән эләктереп алып, җиргә ыргыткан. Чыбыкларның берсен алып кыйнарга тотынган. Башта тимер чыбык белән кыйнаган, анысы сынгач, бакыр чыбык белән кыйнаган, анысы да сынгач, аккургаш чыбык белән каезларга керешкән. Кургаш чыбык бөгелгән, ләкин сынмаган. Мәченең сырты буйлап чыжлый биргән.

Андрей кыйный да кыйный, ә мәче-баюн поплар, дьяклар, поп кызлары турында әкият сөйли икән. Тик Андрей аның әкиятләрен тыңлап тормаган, чыбык белән сыйлавын гына белгән.

Мәченең чыдамы беткән, аңа сүз үтмәсен күргән һәм ялвара башлаган.

— Җибәр мине, яхшы кеше, ни кушсаң, шуны эшләрмен!

— Минем белән барырсыңмы?

— Кая теләсәң, шунда барырмын.

Андрей мәче-баюнны ияртеп кайтып киткән, үз патшалыгына килеп җиткән һәм сарайга барып, патшага болай дигән:

— Алай иттем, болай иттем, йомышыгызны үтәдем, мәче-баюнны алып кайттым!

Патша таңга калган һәм:

— Яле мәче-баюн, бер гайрәтеңне күрсәт әле! — дигән.

Ә мәче-баюн патшаның ак күкрәген ертып, йөрәген тартып чыгарырга теләгәндәй, үткен тырнакларын тырпайтып патшага таба килә башлаган.

Патша курыккан:

— Укчы Андрей, зинһар өчен мәче-баюнны тый!.. дигән.

Андрей мәчене юашландырып читлеккә япкан да, өенә Мария-царевна янына кайтып киткән. Яшь кәләш белән гөрләшеп яши башлаган.

Патшаның йөрәгендә көнчелек уты тагын да ныграк куера башлаган. Ул киңәшчесен чакыртып китергән:

— Ничек итсәң, ит, укчы Андрейның башына җит. Югыйсә минем кылыч — калдырмас башың тыныч!

Киңәшче туп-туры кабакка барган. Анда әлеге ертык чикмәнле эчкечене очраткан һәм котылыр юл, акыл өйрәтүен үтенгән. Эчкече бер стакан аракы эчкәч, мыегын бөтереп:

— Бар, патшага әйт, — дигән ул, — җибәрсен ул аны шунда — белмим кая, китерсен шуны — белмим нине. Бу эшне Андрей беркайчан да үти алмас һәм әйләнеп тә кайтмас.

Киңәшче патша янына йөгергән һәм сөйләп биргән. Патша Андрейны чакырткан:

— Син минем ике йомышымны үтәдең, инде өченчесен дә үтә: Бар, шунда — белмим кая, китер шуны — белмим нине. Үти алсаң, патшаларча бүләкләрмен. Үти алмасаң, минем бу кылыч — калдырмас башың тыныч!

Андрей өенә кайткан һәм утырган да елаган.

Мария-царевна аңардан сораган:

— Нигә син болай кәефсез? Әллә бер-бер хәл бармы?

— Эх, — дигән Андрей, — синең матурлыгың аркасында, күрмәгәнем калмады. Миңа патша: бар шунда — белмим кая, китер шуны — белмим нине табарга кушты.

— Менә бу эш дисәң дә эш. Ярый, зарар юк. Бар ятып йокла, иртә кичтән хәерлерәк.

Мария-царевна төн җиткәнен көткән, тылсымлы китабын алып кат-кат укыган, китабын ташлап, куллары белән башын тотып уйга чумган. Патша табышмагы турында хәтта китапта да бер ни дә язылмаган булган. Мария-царевна өй алдына чыккан да яулыгын болгаган, бөтен кошлар, барлык җанварлар җыелышып килгәннәр. Мария-царевна алардан:

— Әй, урман җанварлары, әй, сез, очар кошлар! Сез бар җирдә дә буласыз, бөтен җирләрне гизәсез. Ишетмәдегезме, нәрсә ул: бар шунда — белмим кая, китер шуны — белмим нине? — дип сораган.

Җанварлар, кошлар җавап биргәннәр:

— Юк, Мария-царевна, безнең ул турыда ишеткәнебез дә юк, — дигәннәр.

Мария-царевна, яулыгын болгаган. Җанварлар да, кошлар да күздән югалганнар. Икенче кат болгаган — каршына ике Алып килеп баскан:

— Ни кирәк? Ни боерасыз?

— Минем турылыклы хезмәтчеләрем, сез мине диңгез уртасына алып барыгыз?

Алыплар Мария-царевнаны диңгез уртасына алып киткәннәр. Диңгезнең иң тирән җиренә кереп, багана кебек басканнар, Мария-царевнаны кулларына күтәреп торганнар. Мария-царевна яулыгын болгаган, аның янына диңгездәге барлык балыклар, барлык җанварлар йөзеп килгәннәр.

— Әй, сез, диңгез җанварлары һәм диңгез балыклары! Сез һәркайда йөзәсез, барлык атауларда буласыз. Ишетмәдегезме, нәрсә ул: бар шунда — белмим кая, китер шуны — белмим нине? — дигән.

— Юк, Мария-царевна, безнең ул турыда ишеткәнебез юк, — дигәннәр.

Мария-царевна кайгыга баткан һәм үзен өенә илтергә кушкан. Алыплар аны Андрейның өй алдына китереп куйганнар.

Иртә таңнан Мария-царевна Андрейны юлга чыгарга җыендырган, аңа бер йомгак җеп һәм чиккән сөлге биргән:

— Йомгакны алдыңа ташла. Ул кай якка тәгәрәсә, син дә шул якка бар. Ләкин кара, кая гына барып керсәң дә, юынганнан соң кеше сөлгесенә сөртенмә, минем сөлгемә сөртен.

Андрей Мария-царевна белән саубуллашып, дүрт ягына баш игәннән соң, юлга чыккан. Йомгакны җиргә ташлаган, анысы тәгәри башлаган. Тәгәрәгән дә тәгәрәгән, ә Андрей аның артыннан ияргән.

Әкият тиз сөйләнә, эш алай ук тиз эшләнми. Күп патшалыклар, күп җирләр үткән Андрей. Йомгак тәгәрәгән дә тәгәрәгән, артыннан җебе сузылып кала барган. Йомгак шул кадәр кечерәйгән, тавык башы хәтле генә калган. Бара торгач ул такыр юл өстендә дә күренмәслек хәлгә килгән. Андрей

бер урманга якынлашкан. Ул тавык аяклары өстенә ясалган бер өйчек каршына килеп чыккан.

— Өйчек, өйчек, миңа алдың, урманга артың белән әйлән!

Өйчек әйләнгән. Андрей аның эченә кергән һәм сүс эрләп утыручы җитен чәчле бер карчык күргән.

— Фу, фу, — дигән карчык, — күзем белән күрмәгән, колагым белән ишетмәгән рус исе бүген үзе монда килгән. Мин хәзер сине мичтә куырып ашармын, сөякләреңә утырып шуармын!

Андрей карчыкка җавап биргән:

— Син нәрсә, убырлы карчык, юл кешесен ашамакчы буласың! Юл кешесе ябык була, керләнеп каткан була. Син элек мунча як, юындыр, чабындыр мине. Аннан ашасаң, ашарсың!

Убырлы карчык мунча яккан. Андрей чабынган, юынган, хатыны биреп җибәргән сөлгесен алып сөртенә башлаган.

Убырлы карчык:

— Бу сөлгене син каян алдың? Аны минем кызым чиккән иде ич? — дип сораган.

— Синең кызың, минем хатыным. Сөлгене миңа ул бирде.

— Ах, сөекле кияүкәем! Сине нәрсә белән генә сыйларга соң инде?!

Убырлы карчык кичке аш хәзерләгән. Табынга ашамлык, эчемлекләрнең, балларның һәртөрлесен куйган. Андрей әрләнеп тормаган, өстәл янына утырган да, алдына куелганнарны сыпырган да сыпырган. Убырлы карчык аның янәшәсенә утырган һәм сораша башлаган — ничек алар Мария-царевна белән өйләнешкәннәр дә ничек торалар.

Андрей карчыкка ничек өйләнешүләрен дә, ничек патшаның: бар шунда — белмим кая, китер шуны — белмим нине алып кайтырга кушканын да, барысын да, барысын да сөйләп биргән һәм:

— Менә, әбекәй, син миңа булышсаң иде! — дигән.

— Ах, кияүкәем, кияүкәем, андый гаҗәп әйбер турында минем дә ишеткәнем юк. Бу турыда белсә, бары тик бер карт бака гына белер. Ул сазлыкта өч йөз елдан артык яши инде. Ярый, зарар юк, син ятып йокла, иртә кичтән хәерлерәк, — дигән.

Андрей ятып йоклаган. Ә убырлы карчык кулына ике яфраксыз каен себеркесе алган да, сазлыкка очкан һәм баканы чакырган:

— Бака әби, сикергеч әби, исәнме әле син?

— Исән әле, исән!

— Чык әле монда, минем янга!

Сикергеч бака сазлыктан чыккан. Убырлы карчык аннан сорашырга керешкән:

— Беләсеңме „шуны — белмим нине“?

— Беләм.

— Күрсәт инде алайса, мәрхәмәт ит. Киявемә: „Бар шунда — белмим кая, китер шуны — белмим нине“, — дигән эш тапшырганнар.



Бака җавап биргән:

— Мин аны теләп озата барыр идем дә, артык картаеп киткәнмен шул. Минем елганы сикереп чыгарлык рәтем калмагандыр инде. Киявең мине яңа сауган сөткә салып ут елгасына тикле алып барсын, шунда карап карармын.

Убырлы карчык сикергеч баканы алып өенә кайткан. Чүлмәккә сөт сауган да, баканы сөт эченә җибәргән. Иртә таңнан Андрейны уяткан:

— Әйдә, тор кадерле кияү, киен, яңа сауган сөт тутырылган чүлмәкне ал. Аның эчендә сикергеч бака ята. Минем атыма атлан. Ат сине ут елгасына кадәр алып барыр. Шунда житкәч, атыңны җибәр дә, баканы чүлмәк эченнән чыгар. Калганын сиңа ул аңлатыр, — дигән.

Андрей киенгән, чүлмәкне алып, убырлы карчыкның атына атланган. Ай киткән, ел киткән, ат ут елгасына барып та житкән. Ут елгасы аяклы сикереп үтәрлек, канатлы очып узарлык түгел икән. Андрей аттан төшкән. Шунда бака аңарга:

— Мине чүлмәктән чыгар, яхшы егет, безгә елга аша үтәргә кирәк, — дигән.

Андрей баканы чүлмәктән алып, җиргә куйган.

— Инде хәзер, яхшы егет, минем аркама менеп утыр!

— Ни сөйлисең, әбекәй, син нинди кечкенә, сытып изәрмен ич үзеңне?!

— Курыкма, измәссең. Утыр да нык кына тотын.

Андрей сикерек бака өстенә утырган. Бака кабара башлаган. Кабарган-кабарган, чүмәлә зурлыгы булган.

— Нык тотындыңмы син?

— Бик нык, әбекәй.

Бака тагын ныграк кабара башлаган һәм карурманнан да югарырак күтәрелгән. Сикергән дә ут елгасының аръягына төшкән. Андрейны да үзе белән алып чыккан. Бака яңадан кечерәйгән.

— Яхшы егет, әнә шул сукмак буйлап кит. Шунда сарай дисәң — сарай түгел, өй дисәң — өйгә ошамаган бер нәрсә күрерсең. Эченә кер дә, мич артына кач. „Китер шуны — белмим нине" шул өйдә табарсың.

Андрей сукмак буйлап киткән. Өй дисәң — өй түгел, тәрәзәсез, болдырсыз, койма белән уратылып алынган бер иске йортка барып житкән. Эченә кергән дә, мич артына качкан.

Күп тә үтмәгән, урман ягыннан дөбердәгән, чиелдаган тавышлар ишетелгән һәм кинәт өй эченә үзе бер карыш, сакалы биш карыш, бер карт килеп тә кергән. Ул:

— Әй, Наум кода, ашарга китер миңа! — дип акырган.

Карт акырудан тукталып та өлгермәгән, кинәт кенә каяндыр бер өстәл барлыкка килгән. Аның өстенә бер мичкә сыра, кыздырылган үгез, үткер пычак куелган булган.

Кыска аяклы, көрәк сакаллы карт үгез янына утырган да, үткер пычакны алып ит кискәләргә, кисәкләрне сарымсакка манчып-манчып ашарга һәм мактарга тотынган.

Карт үгезне соңгы сөягенә кадәр ялап ташлаган, мичкәдәге сыраны да эчеп бетергән. Шуннан:

— Әй, Наум кода, калдыкларны җыйна! — дип кычкырган.

Кинәт кенә өстәл булмагандай юкка чыккан. Сөяк-санаклар да, мичкә дә, берсе дә калмаган. Андрей кыска аяклы карт киткәнне көткән. Мич артыннан чыккан һәм үзенең бар гайрәтен җыеп:

— Наум кода, ашарга китер миңа! — дип кычкырган.

Аның кычкырып җибәрүе булган, каяндыр өстенә һәртөрле ашамлык-эчемлекләр, баллар, закускалар, аш үтемләткечләр тезелгән бер өстәл барлыкка килгән.

Андрей өстәл янына утырган:

— Наум кода, әйдә, рәхим ит табынга, бергәләп ашап-эчик!

Күзгә күренмәс аңа җавап биргән:

— Рәхмәт сиңа, яхшы күңелле кеше! Мин монда бик күп еллар хезмәт иттем, ләкин көйгән икмәк кисәге дә күрмәдем. Ә син мине өстәл янына утыртасың.

Андрей каранган, каранган да, гаҗәпкә калган. Берәү дә күренмәгән, ләкин өстәл өстеннән ашамлыклар да, эчемлекләр дә себерке белән себергән кебек югала барганнар. Бал рюмкага үзе салынган. Рюмка бер менеп, бер төшеп, эчендәге бал һәр күтәрелештә каядыр юкка чыга барган.

Андрей сораган:

— Наум кода, күрен әле миңа!

— Юк, мин бер кешегә дә күренмим. Мин бит „Шул—белмим нәрсә ул“.

— Наум кода, миңа хезмәт итәргә телисеңме?

— Ни өчен теләмәскә? Мин синең яхшы кеше икәнеңне күреп торам ич.

Алар ашап-эчеп туйганнар. Андрей:

— Наум кода, җыеп ал барысын да. Китик моннан! — дигән.

Андрей өйдән чыгып киткән, як-ягына караган:

— Наум кода, син кайда?

— Мин монда, синнән калмам, курыкма.

Андрей ут елгасына барып җиткән. Анда аны сикерек бака көтеп тора икән:

— Әйбәт егет, таптыңмы „Шуны—белмим нине“?

— Таптым, әбекәй.

— Утыр өстемә.

Андрей аның өстенә утырган. Бака кабара башлаган, кабарган-кабарган да, сикергән. Аны да ут елгасы аша чыгарган.

Андрей сикерек бакага рәхмәт әйтеп, саубуллашкан да, үз патшалыгына таба юл тоткан.

Барган-барган да, борылып караган:

— Наум кода, син кайда?

— Мин монда, синнән калмам, курыкма.

Киткән, киткән Андрей бик ерак киткән. Елдам аяклары арыган, ак куллары талган.

— Эх, — дигән ул, — шул кадәр арыдым!

Ә Наум кода җавап биргән:

— Ник син әллә кайчан әйтмәдең? Мин сине күз ачып күз йомганчы урыныңа илтеп җиткергән булыр идем.

Андрейны көчле өермә очырып алып киткән. Таулар, урманнар, шәһәр, авыллар аста күренеп-күренеп кенә калганнар. Андрей тирән диңгез өстендә очканнарын күреп куркуга төшкән:

— Наум кода, ялга тукталсак ни була! — дигән.

Кинәт җил басылган. Андрей диңгез өстенә төшә башлаган. Караган: әле генә зәңгәр дулкыннар шаулаган урында бер атау һәм атау өстендә тирәсе гөл бакчасы белән әйләндерелеп алынган, алтын түбәле бер сарай барлыкка килгән.

Наум кода, Андрейга болай дигән:

— Ял ит, аша, эч, диңгезне күзәт. Озакламас өч сәүдә корабле күренер. Син сәүдәгәрләрне кунакка чакыр, яхшылап сыйла. Аларның өч гаҗәеп әйберләре бар. Син шул әйберләргә мине алмаш. Курыкма, мин кире кайтырмын.

Күпме, азмы вакыт үткән, көнбатыштан өч корабль күренгән. Атауны һәм андагы гөлбакчага күмелеп утырган алтын түбәле гүзәл сарайны корабль хуҗалары да күреп алганнар.

— Бу нинди могҗиза? — дигәннәр алар, — бу тирәдән ничәмә-ничә тапкырлар үтеп киткән булсак та, бу урында зәңгәр диңгездән башка, бер әйбер дә күрмәгән идек, әйдәгез тукталыйк!

Корабльләр якорь ташлаганнар. Корабль хуҗалары җиңел көймәгә утырып, атауга йөзеп чыкканнар. Укчы Андрей аларны каршы алган:

— Әйдәгез, рәхим итегез, кадерле кунаклар!

Корабль хуҗалары — сәүдәгәрләр, ут кебек янып торган алтын түбәгә, агачлардагы сайрар кошларга, юлларда сикергәләп йөргән матур җәнлекләргә карап таңга калганнар.

— Әйтче, хөрмәтле кеше, бу искиткеч гүзәл сарайны кем ясады?

— Хезмәтчем Наум кода, бер төн эчендә ясады.

Андрей кунакларны сарайга алып кергән.

— Әй, Наум кода, безгә ашарга, эчәргә хәзерлә!

Каяндыр өстенә җаның теләгән ашамлык, эчемлекләр тезелгән өстәл барлыкка килгән.

Сәүдәгәрләр аһ иткәннәр:

— Әйдә, — дигәннәр, — хөрмәтле кеше, алыш-биреш ясыйк. Син безгә хезмәтчең Наум коданы бир, безнең гаҗәеп әйберләребездән теләгәнеңне сайлап ал.

— Ни өчен алышмаска? Сезнең гаҗәеп әйберләрегез нәрсә соң алар?

Сәүдәгәрләрнең берсе куеныннан бер тукмак чыгарган.

— Аңа: „Я әле, тукмак, ташла шул кешене тукмап“ — дип кенә әйт, ул хәзер үк үзеннән-үзе тукмакларга тотына һәм нинди генә батырның да кабыргасын сындырып ташлый.

Икенче сәүдәгәр итәк астыннан балта тартып чыгарган, түтәсе белән өскә әйләндергән икән, балта үзеннән-үзе юнырга керешкән. Чапкан саен бер корабль, чапкан саен бер корабль чыккан да торган. Корабльләр җилкәннәр, туплар, гайрәтле моряклар белән тәэмин ителгәннәр, үзләре йөзеп йөриләр, туплары ут яудыралар, моряклар приказ биргәнне генә көтеп торалар икән. Балта түтәсе аска таба каратылу белән барлык корабльләр бер дә булмагандай, юкка чыкканнар.

Өченче сәүдәгәр кесәсеннән быргы чыгарып кычкырта башлаган. Мылтыклар, туплар белән коралланган җәяүле һәм атлы гаскәрләр килеп чыкканнар. Гаскәрләр үткәннәр дә үткәннәр, музыкалар гөрләгән, байраклар җилфердәгән. Атлылар чабышып килгәннәр, приказ сораганнар. Сәүдәгәр быргының икенче башыннан сызгырткан, бары да юк булган.

Укчы Андрей болай дигән:

— Сезнең бу әйберләрегез бик яхшы, ләкин минем хезмәтчем кыйммәтлерәк тора. Әгәр чынлап алышырга теләсәгез, хезмәтчем Наум кода өчен, әйберләрегезнең өчесен дә бирегез.

— Бик күп булып китмәсме?

— Теләсәгез нишләгез, шунсыз алыша алмыйм.

Сәүдәгәрләр уйлаганнар-уйлаганнар да: „Тукмак, балта һәм быргы безгә нигә кирәк? Әйдәгез алыштырыйк. Наум кода белән көне-төне ашап-эчеп кайгысыз яшәргә мөмкин“, — дигәннәр.

Алар Андрейга тукмакны, балта белән быргыны тоттырганнар да кычкырганнар:

— Әй, Наум кода, безнең белән китәргә туры килә сиңа? Турылык белән чын күңелдән хезмәт итәрсеңме син безгә?

Наум кода җавап биргән:

— Ник хезмәт итмәскә! Миңа кайда торсам да барыбер.

Сәүдәгәрләр корабльләренә кайтып, ашарга-эчәргә, сыйланырга керешкәннәр. Ашаганнар да эчкәннәр, акырганнар да бакырганнар:

— Әй, Наум кода, тизрәк юргала! Аны бир дә, моны бир.

Алар тәмам исергәнче эчкәннәр һәм утырган урыннарында ук тәгәрәшеп йоклаганнар.

Андрей сарайда ялгыз үзе генә калгач, борчыла башлаган:

„Эх,—дип уйлаган ул. — Минем туры хезмәтчем Наум кода кайда икән хәзер?“

— Мин монда, ни кирәк сиңа?

Андрей шатланган:

— Наум кода, туган илгә, сөекле хатыным янына кайтыр вакыт җитте бугай. Мине өемә илтеп куй!

Андрейны өермә яңадан күтәреп алып киткән.

Сәүдәгәрләр уянышканнар һәм баш төзәтергә теләгәннәр:

— Әй, Наум кода, безгә тагын ашарга-эчәргә хәзерлә! Тизрәк юргала!

Күпме генә кычкырсалар да, нинди генә тавыш белән чакырсалар да

Наум кода инде килмәгән. Караганнар: Атаудан да җилләр искән булган. Аның урынында зәңгәр дулкыннар гына шаулашканнар.

Кайгырышканнар сәүдәгәрләр: „Эх, юньсез кеше, безне кәкре каенга терәтеп киткән икән!“ — дигәннәр алар. Бер нишләр хәл юк. Җилкәннәрен күтәргәннәр дә, юлларына юнәлгәннәр.

Укчы Андрей үз иленә кайтып җиткән һәм нәкъ үз өе янына төшкән. Ләкин ни күрсен өе урынында күмергә әйләнгән морҗадан башка бернәрсә дә юк икән.

Ул башын түбән иеп, зәңгәр диңгез буена, бер аулак урынга барып утырган. Шунда утыра да утыра икән. Кинәт каяндыр аның янына күк күгәрчен очып килгән һәм җиргә бәрелеп, яшь кәләшкә, Мария-царевнага әверелгән.

Алар кочаклашып исәнләшкәннәр, сорашырга, сөйләшергә тотынганнар.

Мария-царевна болай дигән:

— Син киткән көннән бирле, мин күк күгәрчен булып очып йөрдем. Патша өч тапкыр кеше җибәрде, алар мине таба алмадылар, өебезне яндырдылар.

Андрей әйткән:

— Әй, Наум кода, шушы зәңгәр диңгез буена безнең өчен сарай салырга мөмкин булмасмы икән?

— Нигә мөмкин булмасын? Хәзер үтәлгән булыр.

Алар күз ачып, күз йомарга да өлгермәгәннәр, патша сараеннан яхшырак бер сарай салынып та куелган. Сарай ямь-яшел гөлбакча эчендә утырган, агачларында кошлар чөкердәшкәннәр, юлларында матур җәнлекләр сикерешкәннәр.

Укчы Андрей белән Мария-царевна сарай эченә кергәннәр дә, ачык тәрәзә төбенә утырып, сүзләрен дәвам иттергәннәр, бер-берсенә карап туя алмаганнар. Шулай кайгы-хәсрәтсез берничә көн үткән.

Көннәрдән бер көнне патша зәңгәр диңгез буена ауга чыккан һәм элекке сахра кебек буп-буш бер урында гүзәл бер сарай торганын күргәч:

— Нинди тәрбиясез кеше, сорамый-нитми минем җиремә урнашырга батырчылык иткән? — дип акырган.

Чабышкылар чабышканнар, күзәтчеләр күзәткәннәр, патшага сарайның укчы Андрей тарафыннан салынуын, аның хәзер сарайда Мария-царевна белән яшәвен хәбәр иткәннәр.

Патша тагын да ныграк ачуланган һәм Андрей, „Бар шунда — белмим кая, китер шуны — белмим нине“ артыннан бардымы икән, дип сорарга җибәргән.

Чабышкылар тагын чабышканнар, белгәннәр һәм патшага хәбәр иткәннәр:

— Укчы Андрей „Бар шунда — белмим кая, китер шуны — белмим нине“, дигән җиргә барып кайткан.

Патшаның ачуы тагын да кабарган. Гаскәр җыярга, диңгез буена барып, сарайны нигезенә кадәр җимерергә, укчы Андрей белән Мария-царевнаны иң шәфкатьсез үлем җәзасына тартырга приказ биргән.

Андрей өсләренә куәтле гаскәр килүен күргән, тиз генә балтасының түтәсен өскә табан әйләндергән. Балта юна башлаган. Чапкан саен бер корабль, чапкан саен бер корабль чыккан да торган... Йөз тапкыр чапкан, зәңгәр диңгез өстендә йөз корабль йөзеп йөри башлаган!

Андрей быргысын алып кычкырткан икән, байраклар күтәргән, мылтыклар, туплар белән коралланган җәяүле һәм атлы гаскәрләр барлыкка килгәннәр. Гаскәр башлыклары чабышып килгәннәр, приказ көткәннәр. Андрей сугыш башларга приказ биргән. Музыка уйнаган, барабаннар сугылган, полклар кузгалган. Җәяүле гаскәрләр патша солдатларын туздырганнар, ә атлылар көтмәгәндә һөҗүм итеп, качучыларны пленга алганнар. Йөз корабльдәге йөзләрчә туплар башкалага ут яудырганнар.

Патша үз гаскәрләренең хурлыклы рәвештә качуларын күргән, туктату теләге белән сугыш мәйданына атылып килгән.

Андрей шул вакыт тукмакка әмер биргән:

— Я әле, тукмак, ташла патшаны тукмап!

Тукмак зыр-зыр әйләнгән, әле бер очына, әле икенче очына әйләнә-әйләнә барган да, ялангач кыр уртасында патшаны куып җитеп, маңгаена шундый итеп берне кундырган, патша егылган да дөмеккән.

Сугыш туктаган. Шәһәр халкы кырга чыккан. Алар укчы Андрейдан дәүләтне үз кулына алуын үтенгәннәр.

Андрей да бәхәсләшеп тормаган. Бөтен илгә бәйрәм игълан иткән. Һәм Мария-царевна белән берлектә. гомеренең соңгы көннәренә кадәр, патшалык белән идарә иткән.



А. ТОЛСТОЙ.

ПОДИ ТУДА — НЕ ЗНАЮ КУДА,
ПРИНЕСИ ТО — НЕ ЗНАЮ ЧТО

(на татарском языке)

Тәрҗемәчесе Ш. Зәйни

Техник редакторы *А. Феофилактов*

Корректоры *Н. Исмагилова*

Наборга бирелде 7/X 1950 ел. Басарга кул куелды 5/I-1951 ел. ПФ 01104
Кәгазь форматы 60×92¹/₈-1,75 к. т. Учет.-изд. 2,43 таб. Басма табак 3,5
Табакта 42300 хәреф. Заказ № 0303. Тираж 7000+65.

ТАССР Министрлар Советы янындагы Издательстволар һәм полиграфия идарәсенең Татполиграф типографиясе. Казан, Миславский ур., йорт 9.

Бәясе 1 сум 60 тиен.